МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.05.2018 Казан ш. № 21-72-97

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл кылу буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында” 06.06.2014 ел, №21-72-21 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл кылу буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының норматив-хокукый актларын законга туры китерү максатыннан чыгып, б о е р ы к б и р ә м:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл кылу буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында” 06.06.2014 ел, №21-72-21 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл кылу буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс
министрлыгының
30.05.2018 ел, №21-72-97
боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл кылу буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында” 06.06.2014 ел, №21-72-21 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл кылу буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Бу Регламентта финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек төшенчәсе Министрлыкның үз вәкаләтләре кысаларында түбәндәге функцияләрне үтәвен аңлата:

1) бюджетның хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә эчке дәүләт финанс контрольлеген хәл итү:

а) Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны үтәүгә контрольлек итү;

б) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру турында хисапларның, шул исәптән дәүләт заданиеләрен үтәү турында хисапларның тулылыгына һәм дөреслегенә контрольлек итү;

2) “Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 5 апрель, 2013 ел, № 44-ФЗ Федераль законның 99 статьясындагы 8 өлешендә (алга таба – контракт системасы турында Федераль закон) күздә тотылган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә контрольлекне хәл итү:

а) контракт системасы турында Федераль законның 18 статьясында күздә тотылган сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләре үтәлешенә һәм сатып алуларның нигезләнешенә;

б) контракт системасы турында Федераль законның 19 статьясында күздә тотылгансатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләре үтәлешенә;

в) план-графикка кертелеп, бердәнбер товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) белән төзелгән контрактның башлангыч (максималь) бәясе, контракт бәясе нигезләнешенә;

г) товар җибәрүче (подрядчы, эш башкаручы) контракт шартларын бозган очракта заказчы тарафыннан җаваплылык чараларын куллануга һәм башка гамәлләр кылуга;

д) җибәрелгән товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килүенә;

е) җибәрелгән товарны, башкарылган эшне (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтне учетка алуның документларда үзвакытында, тулы һәм дөрес чагылдырылуына;

ж) җибәрелгән товардан, башкарылган эштән (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәттән файдалануның сатып алуны хәл кылу максатларына туры килүенә;

3) законда күздә тотылган очракларда, җирле бюджетлар үтәлешенә контрольлекне хәл кылу.

Министрлык дәүләт функциясен башкарганда, үтәлешенең ни дәрәҗәдә законлы булуын, учет һәм хисабының дөреслеген билгеләү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча алга таба контрольлекне хәл итә.

Бер контрольлек чарасы кысаларында Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуга бәйле чыгымнарга карата контрольлек эшчәнлеген хәл иткәндә, Министрлыкның Россия Федерациясе бюджет законын үтәүгә һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны үтәүгә контрольлек вәкаләтләре, шулай ук контракт системасы турында

Федераль законның 99 статьясындагы 8 өлешендә күздә тотылган вәкаләтләре тормышка ашырылырга мөмкин.

Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр) һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын алучылар, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлар), Татарстан Республикасы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) тарафыннан эчке финанс контрольлеген һәм эчке финанс аудитын хәл итүгә анализ ясый.”.

2. 1.5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контрольлек объектлары булып тора:»;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) финанс органнары (бюджет средстволарын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр) һәм үзләренә бюджетара трансфертлар бирелгән бюджет средстволарын алучылар) Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар, бюджет кредитларын бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү ягыннан, шулай ук аларның дәүләт (муниципаль) программаларда күздә тотылган тиешле максатчан күрсәткечләргә һәм индикаторларга туры килердәй итеп әлеге средстволардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү ягыннан;”;

“е” пунктчасында “Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү турында килешүләр (шартнамәләр)” дигән сүзләрне “дәүләт контрактлары, алар тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, бюджет средстволарын мондый юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү”дигән сүзләргә алыштырырга;

«к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) гамәлләре контракт системасы турында федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән заказчылар, контаркт хезмәтләре, контрактлы идарәчеләр, сатып алуларны хәл итү комиссияләре

һәм аларның әгъзалары, вәкаләтле органнар, вәкаләтле учреждениеләр, махсус оешмалар.”.

3. 1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт функциясен башкару җайга салына:

Россия Федерациясе Бюджет кодексы;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Российская газета, 2001 ел, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

«Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 5 апрель, 2013 ел, №44-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, №14, ст. 1652, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 ел, №323 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2005, №28, ст. 0652, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек вәкаләтләрен хәл кылу тәртибен раслау турында” 07.02.2014 ел, №67 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2014, №14, ст. 0411, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 05.02.2015 ел, №21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы (Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталы, http://pravo.tatarstan.ru, 2015, 3 март, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

«Финанс-бюджет өлкәсендә контрольлек вәкаләтләрен тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының вазыйфаи затлары тарафыннан тутырыла торган документлар формаларын һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләрне раслау турында” 17.01.2018 ел, №21-72-10 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – 17.01.2018 №21-72-10 Министрлык боерыгы) (Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталы, http://pravo.tatarstan.ru, 2018, 14 февраль) нигезендә.».

4. 1.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанс-бюджет өлкәсендә контрольлекне хәл иткәндә Министрлыкның вазыйфаи затларының хокуклары, бурычлары һәм чикләүләре”.

5. 1.10.1пунктчасының сигезенче абзацында “Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозу.” дигән сүзләрне “, шулай ук Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезендә, хәл ителгән сатып алуларны гамәлдә түгел дип тану турында.” дигән сүзләргә алыштырырга.

6. 1.11.1 пунктчасында:

«б» пунктчасында “Министрлыкның вазыйфаи затлары” дигән сүзләрдән соң “, шулай ук үткәрелгән контрольлек чарасы нәтиҗәләре буенча язмача рәвештә каршы килүләр тапшырырга;” дигән сүзләр өстәргә;

“в” пунктчасында «бу регламент һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә” дигән сүзләрне “закон нигезендә” дигән сүзләргә алыштырырга;

«г» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

7. 1.11.2 пунктчасының «б» пунктчасында “контрольлек чаралары” дигән сүзләрдән соң “, шул исәптән Министрлыкның вазыйфаи затлары запрослары буенча” дигән сүзләрне өстәргә;».

8. 1.12.1 пунктчасында:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: и

«б) ачыкланган Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозуларны юкка

чыгару турында күрсәтмәләр һәм (яки) мондый бозулар нигезендә китерелгән зыянны каплау турында таләпләр. Бу Регламентның 1.3 пунктындагы 2 пунктчасында күздә тотылган вәкаләтләрне тормышка ашырганда – сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында ачыкланган Россия Федерациясе законын һәм башка норматив-хокукый актларын бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәләр. Шул ук вакытта бу Регламентның 1.3 пунктындагы 2 пунктчасының «а» - «в» пунктчаларында күздә тотылган вәкаләтләрне хәл кылу кысаларында әлеге күрсәтмәләр сатып алу башланганчы бирелә;»;

3 пунктчасында “язмача каршы килүләр” дигән сүзләрне “язмача рәвештә каршы килүләр” дигән сүзләргә алыштырырга.

9. 2.1.6 пунктчасында:

бишенче абзацны төшереп калдырырга.

10. 2.3.1 пунктчасында:

икенча абзацта “күчмә тикшерү, ревизия” дигән сүзләрне “контрольлек объектының урнашу урыны буенча контрольлек гамәлләре” дигән сүзләргә алыштырырга»;

алтынчы абзацта “күчмә тикшерү, ревизия” дигән сүзләрне “контрольлек объектының урнашу урыны буенча контрольлек гамәлләре” дигән сүзләргә алыштырырга».

11. 2.4.1 пунктчасының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның контрольлек чаралары планын формалаштыруны, контрольлек эшчәнлеген кабатлауны булдырмау максатыннан, башка дәүләт органнары тарафыннан планлаштырыла (үткәрелә) торган шундый ук контрольлек чаралары турында мәгълүматлардан чыгып, Бүлекләр начальниклары хәл итә.».

12. 2.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2 Планнан тыш контрольлек чаралары түбәндәге очракларда Министр кабул иткән карар нигезендә хәл ителә:

Татарстан Республикасы Президентыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, хокук саклау органнарыннан мөрәҗәгатьләр (поручениеләр), депутатларга сораулар, башка дәүләт органнарыннан,

гражданнардан һәм оешмалардан мөрәҗәгатьләр алынганда, шулай ук Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре ачыкланган очракта;

вазыйфаи бурычларны үтәү барышында контрольлек чарасына җаваплы вазыйфаи зат, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, Министрлык эшчәнлеге өлкәсенә кертелгән мәсьәләләр буенча закон һәм башка норматив-хокукый актларны бозу турында мәгълүматлар алганда;

бу Регламентның 5.1.10, 5.2.5 һәм 5.3.5 пунктчаларында күздә тотылган элегрәк бирелгән күрсәтмәне (танытма) үтәү срогы чыкканда.».

13. 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.7 пунктны өстәргә:

«2.7. Контрольлек объектларының вазыйфаи затларының, хосусый эшмәкәрләрнең һәм физик затларның җаваплылыгы.

Контрольлек объектларының Министрлыкка дәүләт финанс контролелеген хәл кылу өчен кирәкле мәгълүматларны, документларны һәм материалларны тапшырмавы яки үз вакытында тапшырмавы, шулай ук аларны тулы күләмендә тапшырмавы яисә дөрес булмаган мәгълүматлар, документлар һәм материаллар тапшыруы, Министрлыкның вазыйфаи затларының законлы эшчәнлегенә комачаулавы Россия Федерациясе законнында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.».

14. 5 бүлектә:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү контрольлек объектының урнашу урыны буенча контрольлек объектына карата тиешле контрольлек гамәлләрен хәл кылудан һәм күчмә тикшерү актын рәсмиләштерүдән гыйбарәт.»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору (яңарту) турында карар Министр карары белән рәсмиләштерелә, карарда контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору (яңарту) нигезе күрсәтелә. Контрольлек чарасын үткәрүне туктатып тору (яңарту) турында карар күчермәсе контрольлек объекты исеменә җибәрелә.».

15. 5.1.2 пунктчага “кара-каршы тикшерүләр барышында” дигән сүзләрдән соң “һәм Министрлык тарафыннан файдаланыла торган мәгълүмати системалар мәгълүматларына анализ ясау нәтиҗәсендә” дигән сүзләр өстәргә.

16. 5.1.8 пунктчасында:

беренче абзацта “яки” сүзен “һәм (яки)” дигән сүзләргә алыштырырга;

бишенче абзацта “бу Регламентка №4 кушымта нигезендә” дигән сүзләрне “, Министрлыкның 17.01.2018 ел, №21-72-10 боерыгы белән расланган” дигән сүзләргә алыштырырга.

17. 5.1.10 пунктчасында:

беренче абзацында “бу Регламентка №7 кушымта нигезендә” дигән сүзләрне “, Министрлыкның 17.01.2018 ел, №21-72-10 боерыгы белән расланган” дигән сүзләргә алыштырырга;

«а», «б», «в» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) контрольлек объектына күрсәтмә һәм (яки) танытма җибәрү турында һәм (яки) мәҗбүриләү нигезендәге бюджет чараларын куллану турында уведомлениеләр җибәрү өчен нигезләрнең булуы хакында;

б) мәҗбүриләү нигезендәге бюджет чараларын куллану турында күрсәтмә, танытма һәм уведомление җибәрүгә нигезләрнең булмавы хакында;

в) планнан тын күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү турында.»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе бюджет законын һәм контракт системасы турында Федераль законда күздә тотылган таләпләрне бозулар ачыкланган очракта Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.29.3 статьясында, 7.32 статьясының 4, 5, 8 – 10 өлешләрендә, 15.1, 15.11, 15.14 – 15.15.16 статьяларында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 20, 20.1 өлешләрендә, 19.6 статьясында, 19.7 статьясында, 19.7.2 статьясының 1 өлешендә, 19.26 статьясының 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.».

18. 5.1.11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.11. Контрольлек объекты акт алынганнан соң ун эш көне эчендә камераль тикшерү актына язмача рәвештә каршы килүләрен тапшыруга хокуклы, мондый каршы килүләр тикшерү материаллары янына урнаштырыла. Каршы килүләр кулдан

тапшырыла яки, тапшыру турында уведомление белән, почта аша заказлы хат белән җибәрелә.»;

19. 5.1.12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.12. Министр тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате буенча тикшеренү үткәрүне билгеләргә мөмкин.

Тикшеренү нәтиҗәләре буенча бәяләмә рәсмиләштерелә, ул камераль тикшерү материаллары янына урнаштырыла.

Планлы камераль тикшерүләр кысаларында үткәрелә торган тикшеренү әлеге тикшерүләрне үткәрү өчен билгеләнгән сроклардан артып китмәскә тиеш. Тикшеренү бу Регламентның 5.3.1 – 5.3.8 пунктчалары нигезендә үткәрелә.

Кара-каршы тикшерүләр бу Регламент нигезендә күчмә яки камераль тикшерүләр өчен билгеләнгән тәртиптә билгеләнә һәм үткәрелә.

Кара-каршы тикшерүләр үткәрү срогы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

Үзләренә карата кара-каршы тикшерү үткәрелә торган затлар һәм оешмалар, танышу өчен, камераль тикшерү тематикасына кагылышлы мәгълүматлар, документлар һәм материаллар тапшыруга, ә тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең язмача запросы (таләбе) буенча камераль тикшерү тематикасына керүче документлар һәм материаллар күчермәләрен тапшыруга бурычлы, алар кара-каршы тикшерү төгәлләнгәннән соң камераль тикшерү материаллары янына урнаштырыла.

Кара-каршы тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, акт камераль тикшерү материаллары белән кушып бирелә.

Кара-каршы тикшерү нәтиҗәләре буенча кара-каршы тикшерү объектына күрсәтмәләр һәм таныткмалар җибәрелми.».

20. 5.2.4 пунктчасында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерү (ревизия) төркеменең территориягә яки контрольлек объекты бүлмәсенә керүенә комачаулау очрагында, шулай ук күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү вакытында контрольлек объектының вазыйфаи затлары тарафыннан мәгълүматлар, документлар һәм материаллар тапшырмау яки үз вакытында тапшырмау фактлары

буенча тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе Министрлыкның 17.01.2018 ел, №21-72-10 боерыгы белән расланган формада акт төзи.»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документларны өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре финанс, бухгалтерия, хисап документларына, сатып алуларны планлаштыру һәм хәл кылу турында документларга һәм контрольлек объектының башка документларына карата, шулай ук контрольлек объектының вазыйфаи, матди яктан җаваплы затларының һәм башка затларының телдән һәм язмача аңлатмаларыннан, белешмәләре һәм мәгълүматларыннан чыгып, шулардан алынган мәгълүматларга анализ ясау һәм аларны бәяләү юлы белән һәм башка контрольлек гамәлләрен хәл кылу нигезендә башкарыла. Фактта өйрәнү буенча контрольлек гамәлләре карау-тикшерү, инвентарьлаштыру, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза ясау, контроль үлчәүләр алу һәм башка контрольлек гамәлләрен хәл кылу нигезендә башкарыла. Контрольлек объекты эшчәнлеген фактта өйрәнү буенча контрольлек гамәлләрен үткәрү һәм аларның нәтиҗәләре Министрлыкның 17.01.2018 ел, №21-72-10 боерыгы белән расланган формалар буенча тиешле актлар белән рәсмиләштерелә.»;

җиденче абзацта «бу Регламентка № 6 кушымта нигезендә» дигән сүзләрне «, Министрлыкның 17.01.2018 ел, №21-72-10 боерыгы белән расланган” дигән сүзләргә алыштырырга;

унынчы абзацта “төркемнең” дигән сүздән соң “күчмә тикшерү (ревизия) кысаларында контрольлек чараларын үткәрү барышында кирәкле мәгълүматлар (документлар, материаллар) алу мөмкинлеге булмаган очракта” дигән сүзләрне өстәргә;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- контрольлек объекты бухгалтерия (бюджет) учетына ия булмаганда яки контрольлек объекты бухгалтерия (бюджет) учетын алып бару кагыйдәләрен бозып, алга таба тикшерү (ревизия) үткәрүне мөмкин булмаган эшкә әйләндерсә, - контрольлек объекты тарафыннан күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү өчен кирәкле документларны торгызу, шулай ук контрольлек объекты тарафыннан учет һәм хисап документларын тиешле хәлгә китерү чорына;»;

түбәндәге эчтәлектәге егерме беренче абзацны өстәргә:

«- тикшерү (ревизия) өркеменә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында алга таба тикшерү (ревизия) үткәрүне мөмкин булмаган эшкә әйләндерердәй хәлләр килеп туганда, берничек тә ерып чыгып торган хәлләр килеп чыгуны кертеп.»;

егерме икенче абзацта “аның срогы өзелә” дигән сүзләрне “контрольлек объектының урнашу урыны буенча контрольлек чараларын үткәрү срогы өзелә, әмма күп дигәндә алты айга гына” дигән сүзләргә алыштырырга.

21. 5.2.5 пунктчасында:

беренче абзацта “бу Регламентка №7 кушымта нигезендә” дигән сүзләрне “, Министрлыкның 17.01.2018 ел, №21-72-10 боерыгы белән расланган” дигән сүзләргә алыштырырга;

«а», «б», «в» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) контрольлек объектына күрсәтмә һәм (яки) танытма җибәрү турында һәм (яки) мәҗбүриләү нигезендә бюджет чараларын куллану турында уведомление җибәрү өчен нигезләрнең булуы турында;

б) күрсәтмә танытма һәм мәҗбүриләү нигезендә бюджет чараларын куллану турында уведомление җибәрү өчен нигезләрнең булмавы турында;

в) контрольлек объекты язмача рәвештә каршы килүләр тапшырганда планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия) билгеләү турында, күчмә тикшерү (ревизия) нәтиҗәләре буенча чыгарылган йомгакларга йогынты ясардай, тикшерелә торган чорга кагылышлы өстәмә мәгълүматлар, документлар һәм материаллар белән.»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе бюджет законын һәм Контракт системасы турында Федераль законны бозулар ачыкланган очракта, Министрлыкның вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.29.3 статьясында, 7.32 статьясының 4, 5, 8 – 10 өлешләрендә, 15.1, 15.11, 15.14 – 15.15.16 статьяларында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 20, 20.1 өлешләрендә, 19.6 статьясында, 19.7 статьясында, 19.7.2 статьясының 1 өлешендә, 19.26 статьясының 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджетның хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә эчке дәүләт финанс контрольлеге буенча вәкаләтләрне хәл иткәндә Министрлык:»;

түбәндәге эчтәлектәге ундүртенче-унтугызынчы абзацларны өстәргә:

«а) Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетның хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсен җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозулар, Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр), дәүләт контрактлары шартларын, дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын контрольлек объектының кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозу турында мәҗбүри төстә карап тикшерелергә тиешле мәгълүматлардан торган күрсәтмәләр, шулай ук мондый бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын юкка чыгару буенча чаралар күрү турында таләпләр яки бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын кире кайтару турында таләпләрне, әлеге документта билгеләнгән срокта яки срогы күрсәтелмәсә – документ алынганнан соң утыз календарь көне эчендә мәҗбүри карап тикшерелергә тиешле, җибәрә;

б) Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетның хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсен җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозуларны, Татарстан Республикасы бюджетыннан средстволар бирү турында килешүләр (шартнамәләр), дәүләт контрактлары шартларын, дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм займнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын контрольлек объектларының кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәдә күрсәтелгән срокта мәҗбүри үтәлергә тиешле таләпләрдән һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджетына китерелгән зыянны каплау турында таләптән торган күрсәтмәләр җибәрә;

в) мәҗбүриләү нигезендәге бюджет чараларын куллана.

Министрлык бу Регламентның 1.3 пунктындагы 2 пунктчасындакүздә тотылган вәкаләтләрен тормышка ашырганда, Россия Федерациясе законын һәм

сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында башка норматив-хокукый актларны бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәләр җибәрә. Шул ук вакытта бу Регламентның 1.3 пунктындагы 2 пунктчасының «а» - «в» пунктчаларында күздә тотылган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында әлеге күрсәтмәләр сатып алу башланганчы бирелә.

Мәҗбүриләү нигезендә бюджет чараларын куллану Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

Министрлык контрольлек объектына күрсәтмәләр һәм (яки) танытмалар җибәрә, күрсәтмәләр яки танытмалар, аларны җибәрү турында карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә, контрольлек объекты вәкиленә җибәрелә (тапшырыла).»;

егерменче абзацта “Россия Федерациясе бюджет законын һәм бюджетта хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы башка норматив-хокукый актларны бозу” дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

22. 5.2.6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2.6. Контрольлек объекты планлы күчмә тикшерү (ревизия) актына мондый акт алынганнан соң ун эш көне эчендә язмача рәвештә каршы килүләрен тапшыруга хокуклы, каршы килүләр планлы күчмә тикшерү (ревизия) материаллары янына урнаштырыла. Каршы килүләр кулдан тапшырыла яки, тапшыру турында уведомление белән, почта аша заказлы хат белән яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.».

23. 5.3.5 пунктчасының сигезенче абзацында “күчмә тикшерү (ревизия)” дигән сүзләрне “планнан тыш күчмә тикшерү (ревизия)” дигән сүзләргә алыштырырга.

24. 5.3.7 пунктчасын 5.3.6 пунктча дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3.6. Контрольлек объекты үткәрелгән контрольлек чарасы нәтиҗәләре буенча контрольлек чарасы нәтиҗәләре алынганнан соң ун эш көне эчендә язмача рәвештә каршы килүләрен тапшыруга хокуклы, каршы килүләр тикшерү материаллары янына урнаштырыла. Каршы килүләр кулдан тапшырыла яки,

тапшыру турында уведомление белән, почта аша заказлы хат белән яисә электрон документ рәвешендә җибәрелә.».

25. 5.3.8 пунктчасын 5.3.7 дип санарга.;

26. №№ 2, 2а кушымталарда:

“язмача каршы килү” дигән сүзләрне “язмача рәвештә каршы килү” дигән сүзләргә алыштырырга:

«Акт буенча каршы килүләргә бәяләмә” дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

27. Регламентка №№ 4-7 кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга.

28. 7 бүлектә 7.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.9. Аерым шикаятьләрне карап тикшерү тәртибе:

7.9.1. Язмача шикаятьтә шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әлеге шикаятьтә әзерләнелә, кылына торган яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять тиешле компетенциядәге дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

7.9.2. Министрлык яки Министрлыкның вазыйфаи заты әдәпсез сүзләр яки мыскыллау, вазыйфаи затның, аның гаиләсе әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау сүзләреннән торган язмача шикаять алганда, шикаятьтә күтәрелгән сорауларга җавап бирмичә калуга һәм мондый шикаять җибәргән гражданинга хокукларыннан явызларча файдаланырга ярамавы турында хәбәр итүгә хокуклы.

7.9.3. Язмача гаризаны, язучысының почеркы начар булу сәбәпле, укып булмаганда, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул тиешле компетенциядәге дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелми, бу хакта шикаятьне теркәүгә алганнан соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән гражданинга хәбәр ителә – фамилиясен һәм почта адресын укып булган очракта.

7.9.4. Язмача мөрәҗәгать тәкъдим, белдерү яки шикаятьнең асылын билгеләү мөмкинлеген бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, һәм ул тиешле компетенциядәге дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка

карап тикшерүгә җибәрелми, бу хакта шикаятьне теркәүгә алганнан соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән гражданинга хәбәр ителә.

7.9.5. Гражданинның язмача шикаятендә элегрәк җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә инде берничә тапкыр язмача җавап бирелгән сорау булып, шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки фактлар китерелмәсә, Министр, вазыйфаи зат яки вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм, әлеге шикаять элегрәк тә Министрлыкка җибәрелгәндә, әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән хат язышуны туктату турында карар кабул итүгә хокуклы. Шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә әлеге карар турында хәбәр ителә.

7.9.6. Министрлыкка яки вазыйфаи затка җавабы Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырылган сораудан торган язмача мөрәҗәгать алынган очракта, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга мөрәҗәгать теркәүгә алынганнан соң җиде көн эчендә, мөрәҗәгатьтә куелган соравына җавап табу өчен, рәсми сайтның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге электрон адресы турында хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына карата шикаятьтән торган мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

7.9.7. Шикаятькә куелган сорауның асылына җавап бирү дәүләт сере яки федераль закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматларны таратуга китерергә мөмкин булган очракта, шикаятьне җибәргән гражданинга, бу мәгълүматларны таратырга ярамавы сәбәпле, куелган соравының асылына җавап биреп булмау турында хәбәр ителә.

7.9.8. Шикаятьтә куелган сорауларның асылына җавап биреп булмау сәбәпләре алга таба юкка чыгарылган очракта, гражданин янә Министрлыкка яки тиешле вазыйфаи затка шикаять җибәрә ала.

7.9.9. Суд карарына ризасызлык белдерелгән шикаять, теркәүгә алынганнан соң җиде көн эчендә, әлеге суд карарына ризасызлык белдерү тәртибен аңлатып,шикаятьне җибәргән гражданинга кире кайтарыла.».